ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

16.12.2021 № 1773

«2022-2024 елларга Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Алабуга шәһәрендә юл хәрәкәте иминлеген арттыру» муниципаль программасын раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 179 статьясы һәм Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Алабуга муниципаль районы муниципаль программаларын эшләү, гамәлгә ашыру һәм аларның нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау турында» 2014 елның 9 июлендәге 765 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «2022-2024 елларга Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Алабуга шәһәрендә юл хәрәкәте иминлеген арттыру» муниципаль программасын (1нче кушымта) расларга.
2. Алабуга муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына (Э.И. Садыйкова) 2022-2024 елларга Алабуга шәһәрендә юл хәрәкәте иминлеген арттыру буенча муниципаль программа чараларын үтәү максатларында бюджетта каралган ассигнованиеләр чикләрендә финанслауны тәэмин итәргә.
3. Әлеге карар рәсми бастырып чыгарылырга тиеш.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче Л.Ф. Нургаянов